СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.08.2023 г. Заинск № 128

**Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2018 елның 19 декабрендәге 138 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 19.12.2018 елның 19 декабрендәге 138 номерлы “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 9 статьяның 1 пунктының җиденче абзацында “һәм тимер юлларны" сүзләрен алырга;

1.2. 14 статья үз көчен югалткан дип таныйрга;

1.3. 42 статьяның 11нче пунктында «тимер юлларны» дигән сүзләрне алырга;

1.4. 43 статьяның 5 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) тышкы яктырту терәкләрен һәм җәмәгать транспортының контакт челтәрен ремонтлау;»;

1.5. 55 статьясының 3 пунктының 1 пунктчасында «һәм тимер юлларны» сүзләрен алып ташларга;

1.6. 60 статьяда:

а) 1 пунктта "тимер юл транспорты" сүзләрен “җәмәгать транспорты" сүзләре белән алыштырырга;

б) 4 пунктта "тимер юл транспорты" сүзләрен “җәмәгать транспорты" сүзләре белән алыштырырга;

1.7. 61 статьяда «тимер юл транспорты» сүзләрен "җәмәгать транспорты" сүзләре белән алыштырырга;

1.8. 96 статьясының 2 пунктының 1 пунктчасында "тимер юл кичүләре янында" дигән сүзләрне алырга.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Зәй шәһәре башлыгы урынбасары Е. В. Недошивинага йөкләргә.

**Совет рәисе** **Р.Г. Кәримов**